**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

2022 елның 19 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге Юлтимер торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге Юлтимер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

а) җирлек территориясен тезекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен тезекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Юлтимер торак пунктында (Совет ур., Игтисамовлар ур.) урам утларына техник хезмәт күрсәтү;
- территорияне механикалаштырылган һәм кулдан үлән чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, иске авария агачларын кисү (килешү буенча эшләрне түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

б) авыл җирлеге торак пункты чикләрендә автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру:

- Юлтимир торак пункты юлларын кардан чистарту (Совет ур., Игтисамовлар ур.);
- Юлтимер торак пунктында (Совет ур., Игтисамовлар ур.) юлдагы чокырларны ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 кен эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Зыятдинова